**ГРАЖДАННАР ҖЫЕНЫ КАРАРЫ**

Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районы
Яңа Имән авыл җирлегенең Яңа Имән авылы торак пунктында
2023 елда үзара салым кертү турында

**2022 елның 15 ноябре** **№ 2**

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы нигезендә, Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районы Яңа Имән авыл җирлегенең Яңа Имән авылында гражданнар җыены

**КАРАР БИРДЕ:**

1. 2023 елда Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районы Яңа Имән авыл җирлеге Яңа Имән авылы территориясендә I төркем инвалидларыннан, 80 яшьтән өлкәнрәк затлардан, вакытлы хәрби хезмәт узучы, махсус хәрби оперциядә катнашучылардан, көндезге бүлектә укучы студентлардан тыш, яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән 300 сум күләмендә үзара салым кертергә.

2. Алынган акчаларны җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә түбәндәге эшләрне башкару өчен җибәрергә:

1) Яңа Имән авылында урамнарны яктырту объектларын карап тоту һәм аларга хезмәт күрсәтү (энергия саклаучы яктырткычлар сатып алу һәм урнаштыру, урам яктылыгын агымдагы ремонтлау һәм аларга хезмәт күрсәтү);

2) «Беларус-82,1» тракторын тоту-82,1 (ягулык-майлау материаллары, запас частьләр сатып алу, машина йөртүче хезмәтенә түләү);

3) Яңа Имән авылы территориясен җәй көне чабу, җыештыру (килешү буенча эшләр һәм хезмәтләр өчен түләү);

4) янгын машинасын карап тоту (ягулык-майлау материаллары, запас частьләр сатып алу, машина йөртүче хезмәтенә түләү)

5) Яңа Имән авылындагы чишмә территориясен төзекләндерү өчен сатып материаллар алу һәм килешү буенча эшләр өчен түләү

6) Яңа Имән авылы зират юлына таш җәю( таш алып кайту, җәяү, килешү буенча эшләр һәм хезмәтләр өчен түләү)

3. Әлеге карарны Яңа Имән авыл җирлеге мәгълүмат стендларында урнаштыру юлы белән халыкка җиткерергә, Сарман муниципаль районының рәсми сайтында (https://sarmanovo.tatarstan.ru/),- хокукый мәгълүматның рәсми сайтында (http://pravo.tatarstan.ru) кабул ителгәннән соң 7 көн эчендә бастырып чыгарырга.

Сарман муниципаль районы
Яңа Имән авыл җирлеге башлыгы,
гражданнар җыенында рәислек итүче Р. Ф.Гараев